**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2019 Балык Бистәсе штп. № 144пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында

Россия Федерациясе Президенты каршындагы коррупциягә каршы тору буенча Совет президиумының 2010 елның 23 декабрендәге (беркетмә №21) карары белән хупланган Россия Федерациясенең дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль (үзидарәлек) хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Үрнәк кодексына ярашлы рәвештә, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы” һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кайбер башка норматив хокукый актлары нигезендә, шулай ук үзләренең профессиональ эшчәнлекләрен лаеклы башкару өчен үзидарәлек хезмәткәрләренең этика (әдәп) нормаларын һәм хезмәт тәртибе (хезмәт, эш урынында үз-үзләрен тоту) кагыйдәләрен гамәлгә кертү (билгеләү, раслау) максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 28 февралендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында” 35 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 12 августындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 28 февралендәге 35пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертү турында” 210 номерлы карарын.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль (үзидарәлек) хезмәткәрләрен кабул ителгән карар белән таныштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 16 апрелендәге
144 пи номерлы карары белән
расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексы (алга таба – Кодекс) Россия Федерациясе Президенты каршындагы коррупциягә каршы тору буенча Совет президиумының 2010 елның 23 декабрендәге (беркетмә №21) карары белән хупланган Россия Федерациясенең дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль (үзидарәлек) хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Үрнәк кодексына ярашлы рәвештә, 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы" һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кайбер башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнде, шуның белән бергә ул Россия җәмгыяте һәм дәүләтенең гомумтанылган әхлак принципларына һәм нормаларына нигезләнгән.

2.Кодекс Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре аларның нинди вазыйфа биләүләренә бәйсез рәвештә таянырга тиешле һөнәри хезмәт этикасының гомуми принциплары һәм хезмәт тәртибенең төп кагыйдәләре җыелмасы булып тора.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) муниципаль хезмәткә керүче Россия Федерациясе гражданы Кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм үзенең хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырганда аларны, шул исәптән "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен файдаланып, үтәргә бурычлы.

4. Һәрбер муниципаль хезмәткәр Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен барлык булган кирәкле чараларны күрергә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәрбер гражданы үзидарәлек хезмәткәреннән аның белән мөгамәләдә булганда Кодекс нигезләмәләренә туры килә торган тәртипне, үз-үзен тотышын көтәргә хаклы.

5. Профессиональ эшчәнлекләрен лаеклы башкару өчен үзидарәлек хезмәткәренең әдәп нормаларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау, урнаштыру, гамәлгә кертү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен,

гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм үзидарәлек хезмәткәрләре тәртибенең бердәм нормаларын тәэмин итү Кодексның максаты булып тора.

6. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә тиешле әхлак, җәмәгатьчелек аңында муниципаль хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру өчен нигез булып хезмәт итә, шулай ук иҗтимагый аң һәм үзидарәлек хезмәткәрләренең әхлаклылыгы, аларның үзконтроле институты буларак чыга.

7. Муниципаль хезмәткәрләрнең Кодекс нигезләмәләрен белүе һәм үтәве аларның һөнәри эшчәнлегенең сыйфатын һәм хезмәт урынында үз-үзен тотышын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## II. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең төп принциплары һәм кагыйдәләре

8. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең төп принциплары Россия Федерациясе гражданнарының аларның муниципаль хезмәттә булулары белән бәйле тәртибенең нигезе булып тора.

9. Дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдындагы җаваплылыкларын аңлап, муниципаль хезмәткәрләр бурычлы:

а) Башкарма комитетның нәтиҗәле эшен тәэмин итү максатларында вазыйфаи йөкләмәләрен намус белән һәм югары профессиональ дәрәҗәдә башкарырга;

б) кеше һәм гражданның хокук һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау җирле үзидарә органнарының, шулай ук үзидарәлек хезмәткәрләренең дә эшчәнлегенең төп мәгънәсен һәм эчтәлеген билгеләвеннән чыгып эш итәргә;

в) үз эшчәнлеген Башкарма комитет вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырырга;

г) кайсы да булса профессиональ яисә социаль төркемнәрне һәм оешмаларны артыграк күрмәскә, яхшырак дип исәпләмәскә, аерым гражданнар, профессиональ яисә социаль төркемнәр һәм оешмалар йогынтысыннан бәйсез булырга;

д) вазыйфаи йөкләмәләрен намус белән үтәүгә киртә булырдай нинди дә булса шәхси, мөлкәти (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр тәэсире белән бәйләнгән гамәлләргә юл калдырмаска;

е) муниципаль хезмәткәргә кайсыдыр затларның коррупцион хокук бозулар эшләргә күндерү максатыннан барлык мөрәҗәгать итү очраклары хакында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә, прокуратура яки бүтән дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итәргә;

ж) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны үтәргә, муниципаль хезмәт узу белән бәйле йөкләмәләрне башкарырга;

з)сәяси фиркаләр һәм иҗтимагый берләшмәләр карарларының хезмәт урыны эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлегенә юл калдырмаучы гаделлекне сакларга;

и) хезмәт урыны, профессиональ этика нормаларын һәм эшлекле тәртип кагыйдәләрен үтәргә;

к) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән мөгамәлә итүдә нәзакәтлелек һәм дикъкатьлелек күрсәтергә;

л)Россия, Татарстан Республикасы һәм бүтән дәүләтләр халыкларының гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә түземлелек һәм хөрмәт күрсәтергә, төрле этник, социаль төркем һәм конфессияләрнең мәдәни һәм бүтән үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

м) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен намус белән үтәвенә шик тудырырга мөмкин булган гамәл, тәртиптән тыелып калырга, шулай ук Башкарма комитет абруена һәм үзенең репутациясенә зыян салырга сәләтле низаглы вәзгыятьтән сакланып калырга (качарга);

н) мәнфәгатьләр низагы барлыкка килүне булдырмау һәм мәнфәгатьләр низагы килеп чыккан очракларны көйләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында күздә тотылган чараларны күрергә;

о)шәхси характердагы мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, дәүләт, үзидарәлек хезмәткәрләре һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

п) дәүләт органы яки җирле үзидарә органы, аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата халык алдында уй, фикер белдерү һәм бәя бирүдән, алар үзидарәлек хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына кермәгәндә, тыелып калырга;

р) Башкарма комитетта урнаштырылган ачык чыгыш ясау һәм хезмәт урыныннан мәгълүмат бирү кагыйдәләрен үтәргә;

с) Башкарма комитет эше турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткерү буенча гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре эшчәнлегенә хөрмәт белән карарга, шулай ук аларга дөрес мәгълүмат алуда тиешле тәртиптә булышлык күрсәтергә;

т) халык алдында, шулай ук гаммәви мәгълүмат чараларында чыгышлар ясаганда Россия Федерациясе территориясендә товарларның, эшләр, хезмәтләр һәм граждан хокукларының башка объектларының бәһасен, Россия Федерациясе резидентлары арасындагы килешүләр суммасын, барлык дәрәҗәдәге бюджет күрсәткечләрен, үзидарәлек үзләштерүләренең, үзидарәлек бурычларының күләмнәрен билгеләүдән (мәгълүматларны төгәл тапшыру өчен бу кирәк булган яисә законда каралган очраклардан гайре) тыелып калырга;

у)җаваплылыгы өлкәсендә булган ресурслар белән мөмкин кадәр нәтиҗәле эш алып баруны тәэмин итүгә даими омтылырга.

10. Үзидарәлек хезмәткәрләре Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Конституцияләрен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын үтәргә бурычлы.

11. Үзидарәлек хезмәткәрләре үзләренең эшчәнлекләрендә, сәяси, икътисади максатларга ярашлылылыктан яисә бүтән сәбәпләрдән чыгып, законнарны һәм бүтән норматив хокукый актларны бозуга юл куярга тиеш түгел.

## III. Муниципаль (үзидарәлек) хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тәртип стандарты.

12. Муниципаль хезмәткәрләр коррупция күренешләренә каршы торырга һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә аны кисәтү буенча чаралар күрергә бурычлы.

13. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыкка юл куярга тиеш түгел.

Үзидарәлек хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә һәм вазыйфаи йөкләмәләрен башкарганда муниципаль хезмәткәр аның тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен тиешенчә башкаруга тәэсир итә торган яки тәэсир итәргә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгының булуы яисә булырга мөмкинлеге турында белгертергә бурычлы.

14. Муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә керемнәре турында, үзенең һәм гаилә әгъзаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар тапшырырга бурычлы.

15. Муниципаль хезмәткәр аңа кайсыдыр затларның коррупцион хокук бозулар эшләргә күндерү максатыннан барлык мөрәҗәгать итү очраклары хакында яллаучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органына яки бүтән дәүләт органнарына хәбәр итәргә бурычлы.

Коррупцион хокук бозулар кылырга күндерү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары хакында, андый фактлар буенча тикшерү үткәрелгән яисә үткәрелә торган очраклардан гайре, хәбәр итү муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи йөкләмәсе булып тора.

16. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи йөкләмәләрен үтәү белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләр (түләүләр) (акчалата түләүләр, бүләкләр, ссудалар, матди төстә хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорттан файдаланган өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алу рөхсәт ителми. Үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан беркетмә чаралары белән бәйле, хезмәт командировкалары һәм бүтән рәсми чаралар вакытында алынган бүләкләр Башкарма комитет мөлкәте дип таныла һәм акт нигезендә тапшырылалар.

17. Муниципаль хезмәткәр хезмәт мәгълүматын закон нигезендә кабул ителгән Башкарма комитетта гамәлдә булган норма һәм таләпләрне үтәп эшкәртергә һәм тапшырырга мөмкин.

18. Муниципаль хезмәткәр санкцияләнмәгән тарату өчен җаваплы булган яисә (һәм) вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле нигездә аңа билгеле булган мәгълүматның куркынычсызлыгын һәм конфиденциальлеген тәэмин итү буенча тиешле чараларны күрергә бурычлы.

19.Үзидарәлекнең бүтән хезмәткәрләренә карата оештыру-әмер бирү вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр башкалар өчен профессиональлек өлгесе, тел тидермәслек репутацияле булырга, Башкарма комитетта нәтиҗәле эш өчен уңай әхлакый-психологик климат булдыруга ярдәм итәргә тиеш.

20. Үзидарәлекнең бүтән хезмәткәрләренә карата оештыру-әмер бирү вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр бурычлы:

а) мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм көйләү буенча чаралар күрергә;

б) коррупцияне кисәтү буенча чаралар күрергә;

в) үзидарәлек хезмәткәрләрен сәяси фиркаләр һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә катнашуга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска.

21. Үзидарәлекнең бүтән хезмәткәрләренә карата оештыру-әмер бирү вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр үзенең кул астындагы муниципаль хезмәткәрләр коррупцион куркыныч тәртипкә юл куймасыннар, үзләренең шәхси тәртипләре белән намуслылык, риясызлык һәм гаделлек үрнәге күрсәтсеннәр өчен чаралар күрергә тиеш.

22. Үзидарәлекнең бүтән хезмәткәрләренә карата оештыру-әмер бирү вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенә буйсынган хезмәткәрләрнең гамәл кылулары яисә гамәл кылмаулары, әдәплелек принципларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен бозган өчен (әгәр андый гамәл кылуларга яисә кылмауларга ирек куймау буенча чаралар күрмәсә) җаваплы була.

23. Турыдан-туры буйсынулы яисә контрольле мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы үзидарәлек хезмәткәрләре арасында якын туганлык яисә кода-кодагыйлык (ата-ана, ир һәм хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатынның абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) булганда, аларның кайсы да булса берсе үзидарәлек хезмәтенән китү яки үзидарәлек хезмәтенең башка бер вазыйфасына күчү юлы белән тиңдәшле үзидарәлек хезмәте вазыйфасыннан баш тартырга бурычлы.

## IV. Үзидарәлек хезмәткәрләре хезмәт тәртибенең тәкъдим ителә торган әдәп кагыйдәләре

24. Хезмәт тәртибендә үзидарәлек хезмәткәренә түбәндәге конституция нигезләмәләреннән чыгып эш итү бурычы зарур: кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң зур хәзинә булып тора һәм һәрбер граждан шәхси тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, үзенең намусын һәм кешелек дәрәҗәсен яклауга хокуклы.

25. Хезмәт тәртибендә үзидарәлек хезмәткәре тыелып кала:

а)җенесе, яше, расасы, милләте, теле, гражданлыгы, социаль, мөлкәти яисә гаилә хәле, сәяси яисә дини яктан артыграк күрү билгеләре буенча дискриминация характерындагы теләсә нинди фикер белдерүләрдән һәм гамәлләрдән;

б) тупаслыктан, кимсетүле тон күрсәтүләрдән, тәкәбберлектән, башта ук ялгыш булган кисәтүләрдән, хаксызга, урынсыз гаепләүләр белдерүләрдән;

в) янаулардан, кимсетүле тәгъбир һәм каршы сүзләрдән, нормаль аралашуга киртә булырдай яисә хокукка каршы тәртипкә котырта торган гамәлләрдән;

г) хезмәт урынындагы киңәшмәләр вакытында тәмәке тартудан, әңгәмәләрдән, гражданнар белән башка хезмәт элемтәләреннән.

26. Муниципаль хезмәткәрләр үз-үзләрен тотышлары (тәртипләре) белән коллективта үзара эшлекле мөнәсәбәт һәм бер-берсе белән конструктив хезмәттәшлек урнаштыруга ярдәм итәргә бурычлылар.

Муниципаль хезмәткәрләр ихтирамлы, яхшы мөнәсәбәтле, нәзакәтле, игътибарлы булырга һәм гражданнар һәм коллегалары белән аралашканда түземлелек, сабырлык күрсәтергә тиешләр.

27. Муниципаль хезмәткәрнең урындагы вазыйфаларын башкарганда тышкы кыяфәтләре хезмәт шартларына һәм хезмәт чаралары форматына бәйле рәвештә гражданнарның дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына ихтирамлы мөнәсәбәтенә ярдәм итәргә, гомум кабул ителгән эшлекле, рәсмилек, басынкылык, традициялелек, пөхтәлек аерып тора торган стильгә туры килергә тиеш.

## IV. Кодекс нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык

28. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен бозу үзидарәлек хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында әхлакый гаепләнергә тиеш, ә федераль законнарда күздә тотылган очракларда Кодекс нигезләмәләрен бозу үзидарәлек хезмәткәренә юридик җаваплылык чаралары куллануга сәбәп була.

Муниципаль хезмәткәр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен үтәү аттестация үткәргәндә, югарырак вазыйфаларга тәкъдим итү өчен кадрлар резервы формалаштырганда, шулай ук дисциплинар җәзалар биргәндә исәпкә алына.